**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
**IV чакырылыш**
423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**IV созыва**
423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

**КАРАР**
от 08.02.2021ел

**РЕШЕНИЕ**
№07-10

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының
административ комиссиясен төзү турында

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 14 статьясының 1 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетын административ комиссия төзүгә вәкаләтле орган итеп билгеләргә.

2. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетына:

- административ комиссия төзергә;
- административ комиссия составын расларга;
- административ комиссиянең эш регламентын расларга.

3. Актаныш муниципаль районы Советының «Район административ комиссиясе турында» 2006 елның 17 июнендәге 5-1 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмати рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында http://aktanysh.tatarstan.ru «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Муниципаль район Советы Рәисе Э.Н.Фәттахов